Габдрахман Әпсәләмовның тууына 100 ел тулу уңаеннан әдәби календарь оештыру өчен материаллар

Баш өлеше. Габдрахман Әпсәләмовка – 100 яшь.

Портрет. Габдрахман Әпсәләмовның төрле елларда төшкән фотоларын кулланырга мөмкин.

1. Г.Әпсәләмов // Ак чәчәкләр бүләк итте [Текст]: Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. – Казан: Мәгариф, 2001. – Б.2,159.

Габдрахман Әпсәләмов турында өземтәләр:

Әпсәләмовның мирасы татар мәдәниятендә иң күренекле урын алып тора, аның әсәрләрен яратып укыйлар, яшьләргә аның тормыш һәм иҗат юлы зур үрнәк булып тора.

Маһинур Фәйзуллина

(Ак чәчәкләр бүләк итте [Текст]: Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. – Казан: Мәгариф, 2001. – Б.111.)

Татар әдәбиятында иң авыр елларда Әпсәләм берүзе ун ел буена татар халкын татар теле янында тотып торды.

Хәсән Туфан

(Ак чәчәкләр бүләк итте [Текст]: Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. – Казан: Мәгариф, 2001. – Б.36.)

Габдрахман Әпсәләмов татар әдәбиятына бөек хыял өчен көрәш, яшьлек поэзиясе, туган ил халкына зур һәм данлы эшләр башкару романтикасы, батырлык һәм фидакарьлек темаларын алып килде.

Рафаэль Мостафин

(Мостафин Р. Тынгысыз йөрәкле язучы [Текст] / Р. Мостафин // Җаваплылык тойгысы: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан, 1979. – Б.99.)

Габдрахман Әпсәләмов һәр яңа әсәре саен тормышка үтебрәк керде, тормышның яңа катлауларын ачканнан-ача барды, кеше күңелендәге хисләрне дәресрәк сурәтләү чараларын камилләштерүендә дәвам итте.

Гази Кашшаф

(Ак чәчәкләр бүләк итте [Текст]: Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. – Казан: Мәгариф, 2001. – Б.20.)

Габдрахман Әпсәләмовның гомеръязмасы:

1911 ел, 28 декабрь – Пенза губернасының Краснослободск өязе (хәзерге Мордовия Республикасының Рыбкино районы) Иске Аллагол авылында туа.

1919-921 еллар – башлангыч мәктәптә белем ала.

1922-1928 еллар – Мәскәүдә Н.Нариманов исемендәге 27 номерлы татар мәктәбендә белем ала.

1928 ел – ФЗӨ мәктәбенә укырга керә.

1931-1937 еллар – Мәскәү заводларында слесарь һәм токарь булып эшли, техникумда белем ала.

1937 ел – «Совет әдәбияты» журналында «Маһинур» исемле беренче хикәясе басыла.

1938-1940 еллар – М.Горький исемендәге әдәбият институтының татар бүлегендә белем ала.

1940 ел – Татарстан дәүләт нәшриятында яшь әдипнең балалар өчен язылган «Киләчәк безнеке» исемле пьесасы басыла.

1941 ел – «Бәхет кояшы» исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыга. А.Гайдарның «Тимур һәм аның командасы» повестен тәрҗемә итә.

1941 ел, август – язучы фронтка китә.

1941-1943 еллар – Карелия фронтының диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры.

1943-1945 ел май – «Ватан өчен сугышка» газетасының җаваплы секретаре.

1944 ел – Татарстан дәүләт нәшриятында «Төньяк балкышы» дип аталган хикәяләр җыентыгы басыла.

1945 ел, июнь – 1946 ел, апрель – «Сталин сугышчысы» газетасы редакциясендә эшли.

1946 ел – СССР Язучылар союзы члены. «Ак төннәр» повесте басылып чыга.

1947 ел – «Зәңгәр кыя» хикәяләр җыентыгы дөнья күрә.

Чыганак: Габдрахман Әпсәләмов: әдипнең тууына 100 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / ТР Милли к-ханәсе; төз. Р.Р. Гаязова; җав. мөх-ре И. Г. Һадиев. - Казан : Милли китап, 2009. - 32 б.